# Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе “Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 3 б-в сыйныфында татар теле дәресе

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| К | И | Т | А | П | | |
| | С | У | Г | А | Н | |
| К | Е | Р | П | Е | | |
| | М | Ә | К | Т | Ә | П |



# Дәреснең темасы

## «Исем» темасын гомумиләштереп кабатлау.



***1.Исем нәрсәне белдерә?***

**А)эш-хәрәкәтне;**

**Ә)предметны яки затны**

**Б)билгене;**

**В)санны.**

***2.Исем сүз төркеме нинди сорауларга җавап бирә?***

**А)нишли?**

**Ә)кем? нәрсә?**

**Б)нинди? кайсы?**

***3.Исем нәрсә белән төрләнә?***

**А)зат-сан;**

**Ә)килеш;**

**Б)заман;**

**В)тартым.**

***4.Исем нинди җөмлә кисәге булып килә?***

**А)ия;**

**Ә)ия, аергыч;**

**Б)ия, хәбәр, аергыч.**

# Сүзлек диктанты

- *Һөнәр, Казан, аккош, малай, укытучы, әни, Ык, Кандыз, Баулы, Алисә.*



**Уртаклык исемнәр**

Һөнәр
Аккош
Малай
Укытучы
Әни

**Ялгызлык исемнәр**

Казан
Ык
Кандыз
Баулы
Алисә



# Физминутка

- **Татар телендә ничә килеш бар?**
- **Юнәлеш  килеше ничәнче урында тора?**
- **Исемнәр ничә төргә бүленә?**
- ***“Китап”* сүзендә ничә иҗек бар?**
- ***“Кояш”* сүзендә ничә хәреф бар?**



| Килеш исеме | Сораулары | Калын кушымчасы | Нечкә кушымчасы |
|---|---|---|---|
| Баш килеш | Кем? Нәрсә? | - | - |
| Иялек килеше | Кемнең? Нәрсәнең? | -ның | -нең |
| Юнәлеш килеше | Кемгә? Нәрсәгә? Кая? | -га, -ка | -гә, -кә |
| Төшем килеше | Кемне? Нәрсәне? | -ны | -не |
| Чыгыш килеше | Кемнән? Нәрсәдән? Кайдан? | -дан, -тан, -нан | -дән, -тән, -нән |
| Урын-вакыт килеше | Кемдә? Нәрсәдә? Кайда? | -да, -та | -дә, -тә |




# Исемнәрнең килешен билгеләгез, кушымчаларын күрсәтегез

| |
|---|
| кошның |
| җырга |
| табигатьне |
| гомер |
| кешедә |
| урманнардан |
| диңгезгә |
| йөрәктән |



| | |
|---|---|
| кошның | И.к |
| җырга | Ю.к |
| табигатьне | Т.к |
| гомер | Б.к |
| кешедә | У-в.к |
| урманнардан | Ч.к |
| диңгезгә | Ю.к |
| йөрәктән | Ч.к |



# Мөстәкыйль эш

Бу күл (нәрсә?) бик зур. Күл... (......?) исеме – Байкүл. Балалар күл.. (.......?) баралар. Алар күл.. (.......?) яраталар. Күл  (.......?) балыкка бай. Малайлар күл.. (.......?) балык тоталар. Без күл... (.......?) чыгабыз һәм кояшта кызынабыз.



Бу күл (нәрсә?) бик зур. Күлнең (нәрсәнең?) исеме – Байкүл. Балалар күлгә (кая?) баралар. Алар күлне (нәрсәне?) яраталар. Күл  (нәрсә?) балыкка бай. Малайлар күлдә (кайда?) балык тоталар. Без күлдән (кайдан?) чыгабыз һәм кояшта кызынабыз.



# Үзбәя

- -Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшемә дә булыша алам – 5;
- -Әйбәт эшлим, материалны аңладым – 4;
- -Әйбәт эшлим, ләкин иптәшемнең ярдәменә каршы килмим – 3.



# Өй эше

1. Әдәби уку китабыннан төрле килештәге исемнәр булган 5 җөмлә язарга, исемнәрнең килешләрен билгеләргә;
2. Исемнәрне төрле килешләрдә кулланып “Татар теле дәресендә” дигән темага кечкенә хикәя язарга.



# Рефлексия

- -Укучылар, без бүгенге дәрестә нинди теманы кабатладык?
- -Исем нәрсәне белдерә?
- -Нинди сорауларга җавап бирә?
- -Нинди исемнәр була?
- -Исем нәрсә белән төрләнә?



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

